**ГЛАВА**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

22.10.2025 Күләгәш авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ожбуй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ожбуй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 10 ноябрендә 10сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ожбуй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекледәр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче

ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, кулланугa ризамы?

1) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

2) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; хезмәт килешүе буенча түләү; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

3) торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Болын урамындагы юлга салу өчен таш сатып алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);
4) Торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу, куаклыкларны кисү, трактор тоту һәм хезмәт күрсәтү, юлларны кардан чистарту, хезмәт килешүе буенча түләү һәм Ожбуй торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Ожбуй авылы, Болын урамы, 15нче йорт территориясе адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.
4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы В.А.Николаев